ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.11.2023 ел Баулы шәһәре № 221

«Баулы муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 августындагы 307 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Баулы муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 августындагы 307 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 180 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 240 номерлы, 2022 елның 12 апрелендәге 71 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 280 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары һәм аерым типтагы булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәдә:

5 таблицада:

1 графада «Техник укыту бүлекләре (бюролары), оешмаларның кадрлар бүлекләре, производствода кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләре» юлларын, «министрлыклар (ведомстволар)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) Баулы муниципаль районы сайтында

(http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы–
Башкарма комитет җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча
беренче урынбасары И.И. Хөснуллина